ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.12.2019 Казан шәһәре № 5-89/тэ

Куллanучыларга «Тукай Тепло-Газ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 01.12.2017 № 5-58/тэ карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2020 ел өчен үзгәрешләр кертү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләр (тарифлар) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә нигезләнеп, һәм 2020 елга җайга салынулы оешманың план буенча кирәкле тулай табышын тәгаенләштереп, 2020 елга җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) дәвамлы тарифларга төзәтмәләр кертү максатында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2018-2020 елларга «Тукай Тепло-Газ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) тарифлар билгеләү турында» 01.12.2017 № 5-58/тэ карарының 1 нче кушымтасына, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (кушымта итеп бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 05.12.2018 № 5-64/тэ карарына 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 02.12.2019 № 5-89/тэ карары редакциясендә)

«Тукай Тепло-Газ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2018-2020 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынулы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланма пар | | | | Әче һәм редукция-ләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 $кг/см^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 $кг/см^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 $кг/см^2$ кадәр | 13,0 $кг/см^2$ югары | |
| | Тукай муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Тукай Тепло-Газ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 2008,08 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 2086,27 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 2086,27 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 2137,83 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 2137,83 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 2199,15 | - | - | - | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге